КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 781

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 952 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 29 апрель, 359 нчы; 2019 ел, 6 сентябрь, 797 нче; 2019 ел, 25 октябрь, 957 нче; 2020 ел, 31 гыйнвар, 62 нче; 2020 ел, 11 февраль, 98 нче; 2020 ел, 12 май, 381 нче; 2020 ел, 3 июнь, 464 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12*);

Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 нче пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш), шулай ук Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан әлеге оешмалар филиалларының белем бирү эшчәнлеген лицензияләү (01.18*);

мәгариф белән идарә итү (04.05*);

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән белем бирү оешмалары типлары һәм белем бирү дәрәҗәләре яктылыгында мәгариф белән идарә итү (04.05.01*);

мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 нче пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш) эшчәнлеген, шул исәптән мәгариф өлкәсендә инвалидлар өчен әлеге оешмалар объектларыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле файдалана алу һәм хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итүне, шулай ук мәгариф өлкәсендә шулай ук идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген дәүләт тикшерүендә тоту (аларга күзәтчелек итү) (04.05.02*);

опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру (04.05.03*).»;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән шәһәр төзелеше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.05*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәткәндә һәм бетергәндә, янгын куркынычсызлыгы

---

*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.14*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән бәяләрне (тарифларны) җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.08*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*).»;

3.3 нче пунктның туксанынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәгариф өлкәсендә муниципаль идарәне гамәлгә ашыручы муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма-боеру органнары (җирле администрацияләр) вазыйфаи затларын (җирле администрацияләр башлыклары урынбасарларын, җирле администрацияләрнең структур бүлекчәләре яки җирле администрацияләрнең тармак органнары җитәкчеләрен) билгеләүне килештерүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин